СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**26.01.2016 ел** **№ 13**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2016 елның 22 гыйнварындагы 12 нче номерлы Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты карары нигезендә Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2016 елның 13 мартына Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

«2016 елда Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү (түләү күләме 100 сум тәшкил иткән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен) 1әм акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - юлларга вак таш салу:<br>Яңа Кырлай авылы,Тукай урамы,29 йорттан 95 йортка кадәр;<br>Яңа Иябаш авылы, | 75500<br><br><br><br>50000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Төхвәтуллин ур.<br>Өчиле авылы, Тукай урамы<br>-юллардагы чокырларны ремонтлау<br>Чиканас авылы (Совет ур., Октябрь ур.); | 16000<br><br>28000 |
| 2 | Күмү урыннарын карап тоту | -зират коймаларын урнаштыру һәм карап тоту:<br>Иске Юрт авылы<br>Югары Бирәзә авылы<br>Күкчә-Бирәзә авылы | <br>7500<br>14000<br>5 000 |
| | | Барлыгы: | 196000 |

әйе юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк ур., 3 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Өчиле авылы, Тукай ур., 73 йорт.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров